**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2023 Балык Бистәсе штп. № 356пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 16.12.2021 №273 пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының өченче абзацы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 16.12.2021 №273пи карары белән

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.11.2022 №324пи, 07.07.2023 №211пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә , "Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының 811" бүлеген түбәндәге эчтәлектәге юл белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 811 | 2 02 45179 05 0000 150 | Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбияләү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек буенча директор киңәшчеләренең эшчәнлеген тәэмин итү чараларын уздыруга муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

2. Әлеге карар 2023 ел бюджетыннан башлап 2024 һәм 2025 еллар план чорына (2023 елга) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов